СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

НУРЛАТ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА НУРЛАТСКОГО РАЙОНА.

5 СЕНТЯБРЬ, 1998 ел. ШИМБӘ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 101 (8258) | Бәясе билгеләнгәнчә

## НУРЛАТТА - СӘНГАТЬ МӘКТӘБЕ

*"...Бина иске иде... Түбә түбәнәя барды, идәннәр шыгырдый, тәрәзәләр ишелә торды... Ә музыка агылды да агылды... һәм менә, ниһаять..."*
*(Балалар чыгышыннан).*

...Тулыр - тулмас өч ел дигәндә, хан сарае төсле мәһабәт бина калкып чыгар дип кем уйлаган? Дөресрәге, уйлаучылар да, хыялланучылар да, шуңа талпынып караучылар да күп булган. Әмма аның татлы хыялдан сөенечле чынбарлыкка әверелүе төзелеш Ф.Х.Мөхәммәтшин исеме белән бәйләнгәч кенә насыйп булуын беркем яшерми. ТРның Дәүләт Советына Нурлат районыннан депутат (ул чакта ТРның Премьер - министры) Фәрит Хәйрулловичның бу бинаны төзелеш планына керттерү, өзлексез финанслау, эш барышын һәрдаим контрольдә тоту, кирәк чакта кирәк кешеләренә "эссе парын" бирү һәм тагын бик күп мәшәкатьләрне хәл итүдә хезмәте, өлеше бәяләп бетергесез. Бина проект бәясеннән шактый кыйммәткәрәк төшә - аны да Фәрит Хәйруллович хәл итә. Җиһазлар, музыка инструментлары алуга гына да 750 мең сум акча кирәк була, анысын кайгырту да депутат җилкәсенә төшә. Шуңа да сәнгать мәктәбен ачу тантанасында Ф.Х.Мөхәммәтшин беренче номерлы кунак, сүзендә торучы депутат кына түгел, бу вакыйгага иң эчкерсез сөенүчеләрнең берсе дә булгандыр, мөгаен. Ә икенчесе - һичшиксез!- район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллин иде. Бу мәһабәт сәнгать сараен торгызуда Фәрит Хәйруллович белән бергә янып - көеп йөрүче, төзүчеләр, мәктәп җитәкчелеге белән һәр проблеманың асылына үтеп хәл итәргә алынучы хаким үзе ике ел җитәкчелек итү чорында инде ничәнче тапкыр шундый бәхетле мизгелләрне кичерә һәм аның чын бәһасен ай - һай әйбәт белә иде. Шуңа да үз чыгышында нурлатлыларны Белем көне белән котлап, бу көнне икеләтә бәйрәм иткән вакыйга өчен иң зур рәхмәтне шәһәрлеләр исеменнән Ф.Х.Мөхәммәтшинга юллады. Фәрит Хәйруллович исә үзе районның иҗади хезмәттә яшәвен зур канәгатьлек белән билгеләп үтте, үҗәтлек һәм тырышлык күрсәткән һәркемгә рәхмәт белдерде. Ә иң җылы рәхмәт сүзләрен укытучыларга юллады, республика, район мәгариф хезмәткәрләренең намуслы хезмәтенә соклану белдерде.

(Ахыры 4нче биттә).








*Рәсемнәрдә: Дәүләт Советы рәисе котлый; менә ул күптән көтелгән символик ачкыч; бүләкнең иң беренчесе - мәктәпне төзеткән остага; нинди күркәм бина килеп чыкты.*

*Н.АЗИЗОВ фотолары.*



## 6 сентябрь - Нефть һәм газ промышленносте хезмәткәрләре көне
## Бәйрәм котлавы

*Кадерле нефтьчеләр һәм кара алтын эзләүчеләр, шушы тармакка мөнәсәбәтле барлык һөнәр ияләре! Сезне һөнәри бәйрәмегез белән ихлас күңелдән котлап, гаять мәшәкатьле, әмма бүген илгә - көнгә элеккегедән дә кирәгрәк хезмәтегезне башкаруда сабырлык һәм күңел көрлеге телим. Татарстан нефтьчеләренең быелгы профессиональ бәйрәме Ромашкино нефть ятмасын эшкәртә башлауга илле ел тулган көннәргә туры килүе белән дә истәлекле. Шушы вакыт эчендә Татарстан нефтьчеләре миллиардлаган тонна җир мае чыгарып илнең икътисадый хәлен тотрыклы итүгә гаять зур өлеш керттеләр. Бүген, нефть базарында хәл бик киеренке булуга да карамастан, сез үз алдыгызга куелган җитештерү программасын эзлекле үтәү өчен бар тырышлыгыгызны куясыз, нигездә кыр шартларында бара торган киеренке хезмәт вахтагызны намус белән дәвам итәсез. Районыбыз территориясендә тагын бер яңа нефть - газ чыгару идарәсе оешу, шуның базасында нефть эшкәртү заводы да корылып килү районның һәм шәһәрнең икътисадын үстерүгә, Нурлатның социаль йөзен тамырдан үзгәртүгә зур өлеш керткән нефтьчеләрнең киләчәктә дә безнең ныклы ышанычыбыз һәм таянычыбыз буласына өмет уята. Һәм без бүгенге катлаулы шартларда да сезнең гомерлеккә сайлаган авыр һәм мактаулы һөнәрегезгә тугрылык саклап, алга таба да җаваплы вахтагызны дәвам итәрсез дип ышанабыз һәм барчагызга да ныклы сәламәтлек, күңел көрлеге, гаиләләрегезгә иминлек һәм бәхет телибез.*

**Ф.С.СИБАГАТУЛЛИН,**
**халык депутатларының берләштерелгән Советы рәисе, район һәм шәһәр хакимияте башлыгы.**

(Бәйрәмгә багышланган язмаларны 2нче биттән укыгыз).

*Номерга хат*

## ЯРДӘМ ИТСӘГЕЗ ИДЕ

***Бисмиллаһир рәхманир рәхим!***

***Газиз милләттәшләребез!***

Татар зиратының тыгызлыгы турында күп тапкырлар сөйләнде инде. Ниһаять, Түбән Нурлат белән тимер юл бистәсе арасында 9 гектарда зират өчен аерым урын бүленде.

Хәзер мәңгелек йортыбызны тәртипкә китерү, тирәләрен тоту мәшәкате белән йөрибез. Шул уңайдан шәһәр кешеләренә, оешма - предприятие җитәкчеләренә мөрәҗәгать итәбез: зинһар, хәлдән килгәнчә, безгә ярдәм итегез. Сезнең игелегегезгә исәп тотабыз, ярдәм күрсәтергә теләүчеләрнең тимер юл мәчетенә мөрәҗәгать итүләрен сорыйбыз.

**Зәкиулла хәзрәт ӘХМӘТШИН.**

## РӘИС АЛЫШЫНДЫ

3 сентябрь көнне нефтебаза ярдәмче хуҗалыгы әгъзаларының гомуми җыелышы булды .Анда оештыру мәсьәләсе каралды.Ярдәмче хуҗалык рәисе итеп **Мөбәрәкҗан Газыйм улы ДӘҮЛӘТШИН** сайланды.

## СЕНТЯБРЬДӘ - АВЫР КӨННӘР

***Сентябрь аенда һава атмосферасында магнит давыллары көчәю ихтималы булган көннәр һәм сәгатьләр:***

**6, шимбә (18.00-20.00),**
**13, якшәмбе (17.00-19.00),**
**15, сишәмбе (16.00-18.00),**
**20, якшәмбе (18.00-20.00),**
**27, якшәмбе (3.00-5.00),**
**28, дүшәмбе (17.00-19.00).**

***Сәламәтлегегезгә игътибарлы булыгыз!***

## ОЧРАШУ УРЫНЫ - ХАСТАХАНӘ

***Пәнҗешәмбе көнне Нурлат районы һәм шәһәре хакимияте башлыгы, ТРның халык депутаты Ф.С.СИБАГАТУЛЛИН район үзәк хастаханәсенең өлкән медицина хезмәткәрләре - табиблар белән очрашты.***

- Табиблар белән очрашу, бөтен проблемаларны уртага салып бер гаиләдәгечә сөйләшү теләге күптән туган иде инде. Ләкин моны төрле сәбәпләр тоткарлап торды.

Хакимият башлыгы сүзен шулай башлады. Аннары ул илнең финанс - икътисадый тотрыксызлыгы, шул сәбәпле республикада һәм районда да хәлнең көннән - көн катлаулана баруы турында сөйләде һәм бүгенге хәлгә карата үз фикерен, позициясен белдерде. Шунда ук авыл хуҗалыгының һәм шәһәр предприятиеләренең бүгенге катлаулы яшәеше белән таныштырды, җитештерүнең көннән - көн кыскаруы нәтиҗәсендә бюджетка акча керү кимүе турында хәбәр итте һәм бюджеттагыларга хезмәт хакы бирелүнең тоткарлыкларын шул факт белән аңлатты, алга таба да хәлнең тагын да катлаулануына, бәяләрнең тагын да күтәрелүенә әзер булырга кирәклеген әйтте. Бүгенге көннең күңелсез яклары турында сөйләүдән соң аның чыгышында оптимистик ноталар да урын алды. Мәсәлән, шикәр чөгендеренең өметле күренүе, Зүзәй нефть промыселының НГДУ статусын алуы һәм башкаларның бюджет файдасына эшләячәге хәбәр ителде.

- Балачагымнан ук хәтерлим: бүгенгедән дә кырысрак вакытлар булды, әмма халыкның кәефе көр иде, ул кечкенә вакыйгага да ихлас шатлана белә иде. Бүген шул чактагыча яшәүгә омтылып, кызыксынуның әсәре дә юк кешеләрдә,- дип, ул халыктагы шул нечкә кылларны уяту,аның рухын күтәрүдә ак халатлы һөнәр ияләренең роле зур, дигән фикерен белдерде.

Ә медицина хезмәткәрләренең үз проблемалары, ихтыяҗлары да аз түгел. "Шуларның иң хәлиткече - торак мәсьәләсе һәм командировка чыгымнары өчен түләүләрнең бер елдан артыкка сузылуы",- дип атады үзәк хастаханәнең баш табибы А.Л. Клементьев. Профком рәисе Н.М. Лисюков: "Сәламәтлек саклау системасында реформа район медицина учреждениеләрендә 135 койканы кыскарту белән яный",- дип хакимият башлыгының бу мәсьәләдә ярдәмен сорады.

Ф.С.Сибагатуллин хастаханә җитәкчелеге таләпчәнрәк, ныклырак торганда, яңа, әле кулланылмаган сыгылмалы юллардан файдаланганда,проблемаларның уңай хәл ителерлек дәрәҗәдә булуына ышаныч белдерде.

**Ф.ГАЛИМОВА.**

# Иртәгә - нефть һәм газ промышленносте хезмәткәрләре көне

## ЧЫДАМЛЫЛЫККА СЫНАУ

Бәйрәм бәйрәм инде. Әйдәп баручы эшче һөнәр ияләренең берсе - Нефтьчеләр көне моннан нәкъ 33 ел элек кертелгән. Ел саен, сентябрьнең беренче якшәмбесендә данлы һәм кыю кешеләрнең хезмәт даны бәйрәме буларак билгеләп үтелә ул.

Шушы вакыт эчендә беренче тапкыр быел нефтьчеләр көне гаять катлаулы шартларда уза. Тышкы һәм эчке базарда да нефтькә бәянең кискен төшеп китүе Россия нефть компанияләре, шул исәптән "Татнефть" АҖ өчен дә чын мәгънәсендә икътисадый фаҗигагә әйләнде. "Татнефть" җитәкчелеге җәмгыятьнең бүгенге финанс - икътисадый хәлен чиктән тыш авыр дип бәяли. Акционерлар җәмгыятендә әле апрельдә үк икътисадны савыктыру өчен гадәттән тыш чаралар кертелүе турында игълан ителде.

Башка структур подразделениеләр белән беррәттән, "Нурлатнефть" нефть - газ чыгару идарәсе дә хуҗалык исәбенең кырыс кысаларына куелды. Баръяклы экономия һәм һәр нәрсәдә тәртип - предприятиенең бүгенге эшчәнлегендә төп таләпләр шул. Барлык чыгымнар да - транспорт, электр энергиясе, капиталь төзелеш, хәтта командировка чыгымнары да ныклы контрольгә алынды. Нефть чыгаручылар алдына нефтьнең һәр тоннасына китә торган эксплуатация чыгымнарын киметү бурычы куелды.

Шундый кыенлыкларга да карамастан, коллективта җитештерү планнарын үтәү өчен киеренке эш бара. Агымдагы елның 8 аенда идарә җир куеныннан 1022250 тонна кара алтын чыгарды, шуның 16290 тоннасы - нормадан тыш. НГДУ эшчәнлек алып бара торган территориядәге уртак предприятиеләр чыгарган нефть 74307 тонна булды.

Килеп туган хәлнең катлаулылыгына, хезмәткә түләүдәге тотрыксызлыкка карамастан, идарә коллективы ярыйсы гына ипле гадәти тормыш белән яши. Элеккеге еллардагы кебек үк, барлык цехлар һәм подразделениеләр дә җитештерү - икътисадый ярышта, җитештерү культурасы буенча смотр - конкурста катнаштылар. Комиссияләр уздырган тикшерүләр күпчелек цехлар һәм участокларда җитештерү заданиеләрен үтәүгә бик җитди караганлыкларын, промышленность объектлары территорияләрен төзекләндерү һәм яшелләндерү, күргәзмә агитацияне яхшырту буенча зур эш башкарганлыкларын күрсәтте. Беренче төркемгә кергән цехлар арасында катламнардагы басымны саклау (начальнигы Д.М.Борһанов), 2нче нефть һәм газ чыгару (Д.Г.Мөхәммәтшин) цехлары, икенче төркемдә пар һәм су белән тәэмин итү цехы (А.И.Сергеев) призлы урыннарга чыктылар. 3нче нефть һәм газ чыгару цехының (Ф.Х.Садретдинов) һәм технологик транспорт идарәсенең (И.Г.Вәлиуллин) әйбәт эшләгәнлекләре билгеләп үтелде.

Еллар буе килгән традиция буенча, һөнәри бәйрәм алдыннан быел да осталык конкурслары, янгын - гамәли спорты буенча ярышлар уңышлы үтте.

Һәр өлкәдәге кебек үк, бездә дә эшнең уңышы - осталыкта. "Нурлатнефть" идарәсенең ике меңле коллективында үз эшенең чын осталары булган йөзләрчә кешеләр бар. Аларның күбесе хаклы рәвештә хезмәт алдынгысы дигән исемне йөртә. Моны идарә администрациясе һәм профсоюз комитетының күптән түгел генә 88 кешене нефть промышленностенда күпьеллык һәм намуслы хезмәтләре, эштә югары күрсәткечләре өчен кыйммәтле бүләкләр һәм акчалата премияләр белән билгеләп үтүе дә ачык раслый. Бүләкләр арасында "Татнефть" АҖнең хөрмәтле нефтьчесе" дигән исем бирелү дә, җәмгыятьнең Мактау тактасына кертелү, АҖнең һәм идарәнең Мактау кәгазьләре белән бүләкләү, "Елның иң яхшы остасы", "Һөнәре буенча иң яхшы", "Иң яхшы рационализатор" исемнәре бирелү һәм рәхмәт белдерүләр дә бар.

Бәйрәм була да уза, ә тормыш дәвам итә. Нурлат нефть чыгаручылары алга таба да үз алларына куелган зур бурычларны башкару эшендә тиешле югарылыкта булырлар дип ышанасы килә.

Соңгы еллардагы базар шартларының чамасызлыгына да карамастан, Нурлат нефтьчеләре яшәүчәнлекләрен саклау һәм барлык көчләрен туплау тәҗрибәсен үзләштерделәр һәм бу аларга нинди генә кыенлыкларга да карамастан төпкә китмәячәкләренә ышаныч бирә. Идарә коллективның үзәген саклап кала алды һәм кыенлыкларны бергәләп җиңү, хезмәт уңышларына бергәләп сөенү, уртак бәйрәмнәр аркылы берләшкән коллективыбыз шушы гаять борчулы чорның да сынауларын ерып чыгачак.

**В.БУРАЙКИН.**



*Рәсемдә: 1нче нефть - газ чыгару цехыннан В.Н.Сенькин, В.В.Абрамов, О.Н.Жирнов, Р.Р.Садыйков, Н.М.Мөхәммәтҗановлар. Алар идарәнең быелгы һөнәри осталык конкурсында беренче урынны алдылар.*

**Н.КВАШНИНА фотосы.**

## БЕРЕНЧЕ НОМЕРЛЫ ЭШЧЕ



Әйе, нәкъ шулай булды: моннан 12 ел элек буш Зүзәй ягы кырында бердәнбер вагончыктан башланган Зүзәй нефть һәм газ чыгару промыселына эшкә урнашырга килгәндә, яңа оешмада бары бер кеше - начальник Ф.И. Галимов кына бар иде әле. Владимир Николаевич үзенең моңарчы Мамык кирпеч заводында эшләвен, нефтьче белеме бөтенләй булмавын яшермәде. Бары өстәде: эшлисем, өйрәнәсем килә, диде. Шулай итеп, В.Н.Долгов бүгенге Зүзәй нефть - газ чыгару промыселының беренче номерлы эшчесе булып теркәлде һәм 12 ел инде шуннан кузгалырга да җыенмый. Өйрәнде Долгов нефтьче хезмәтенә, әле ничек кенә өйрәнде! Ул чакта база янәшәсендә үк куелган 916нчы сиртмә - станок - аның нефтьче биографиясе башындагы беренче практик эш урыны. Ул аңа бүген дә беренче бала кебек үк якын, кадерле. Ул чактагы баш инженер В.П.Воронцов беренче эшчеләрне күп нәрсәгә өйрәтеп калдырды. Теоретик белемне НГДУның укыту - курс комбинатында алдылар. Долговның аягы җиңел булды: яңа эш урынына теләкле, булдыклы эшчеләр тиз тупланды һәм алар барысы да диярлек Владимир Николаевич янәшәсендә һөнәргә өйрәнделәр, яшь коллективның иң "өлкәне"н әйдәп баручы итеп таныдылар. Шулай итеп, берничә ел дәвамында Долгов операторларның "өлкәне" вазифасын үтәде, инде менә ул - нефть чыгару буенча операторлар бригадиры. Ни өчен нәкъ менә аны сайлаганнар?

- Ул һәр скважинаның барлык параметрларын белә, тәҗрибәле, эшенә гаҗәеп җаваплы карый. Кешеләр белән мөнәсәбәте дә гади, гадел, шул ук вакытта принципиаль,- дип аңлата аның серен промыселның профсоюз комитеты рәисе Н.П.Липатов. Операторлар да шул фикердә. Үзләренең бригадирлары турында күп уңай фикерләр санап китә алалар алар. Оператор хезмәте - нефть тармагында иң төп, иң мөһим хезмәт бит. Ул нефть чыгара, станок - сиртмәләргә, җир өсте җиһазларына хезмәт күрсәтә. Техника катлаулы, эш җаваплы, шуңа белем дә, җаваплылык та, дисциплина да ай - һай зур таләп ителәбиредә! Шул шартларның үтәлешен иң әүвәл бригадирдан таләп итәләр. Андый - мондый көтелмәгән хәл килеп туса, иң әүвәл Долговны чакырып китерәләр.( Әле ярый якында - Мамыкта гына тора!). Ни дисәң дә бүген промыселда 70 скважина хәрәкәттә бит - аз, кечкенә күләм түгел бу.

Владимир Николаевич үзе дә бригада әгъзаларыннан канәгать. Арада иң намуслы, белемлеләрен горурлык белән телгә ала. Әйтик, Сергей Белогубов - бер дигән оператор, принципиаль, эшкә бирелгән. Евгений Глебов - икенче ел инде "Татнефтепром" берләшмәсе күләмендә операторлар арасында уздырылган һөнәр осталыгы конкурсында беренче урынны ала. Быел Чирмешәндә үткәрелгән шундый ярышта сокланмаган кеше калмаган үзенә. Нефть техникумы тәмамлап эшләүче М.Гайсинга да өметләре зур. Ә тулаем алганда, бригадасындагы 18 кешенең һәрберсе - обходчигы да, нефть чыгару операторы да үзенчә якын бригадир өчен. Үзе шунда һөнәр алганлыктан, яңа килгән һәркемне эшкә иренмичә өйрәтергә тырыша. Кеше үз гомерен кара алтын чыгаруга багышларга җыена икән - ул күп белергә, иренмәскә, өйрәнергә тиеш, дип саный бригадир һәм үзе белгәннәрнең гамәли ярдәме тиюен күреп чын күңелдән шатлана. Заманалар ничек кенә үзгәрсә дә, үзе ул нефтьче һөнәрен бик дәрәҗәле, мәртәбәле эш итеп саный. Әнә авылдашлары да аңа бер башка өстен итеп карыйлар бит. Биредән ул бер дигән фатир алды, инде менә хатыны Елена Николаевна да монда килеп урнашты. Кем белә, бәлки, үсеп килүче ике балалары да әтиләре сөеп башкарган эшне үз итәрләр, Долгов фамилиясе промысел елъязмасында алыштыргысыз урын алыр? Әти кеше каршы түгел. Беренче номерлы эшче В.Н.Долгов нефтьче һөнәрен дөньядагы иң мавыктыргыч, мөһим, горур һөнәрләрнең берсе итеп саный.

**С.НУРУЛЛИНА.**

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

## БАРЫБЕР ӨМЕТНЕ ӨЗМИЛӘР

Нурлатта разведка бораулавы конторасы оешкан чордан - 1949 елның 25 ноябреннән соң нинди генә үзгәрешләр булмады инде. Яңадан - яңа бригадалар, цехлар оешты, күп кенә яңа исемнәр, казанышлар һәм, билгеле инде, проблемалар да барлыкка килде.

Сугыштан соңгы авыр елларда коллективыбызга нигез салып, аны үстергән, традицияләрен баеткан ветераннарыбызны һәрчак истә тотабыз. Алар арасында Социалистик Хезмәт Герое З.Т.Тимерҗанов, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены кавалерлары М.Г.Галимов, И.И. Гарифуллин, Ю.В.Полуян, С.Ш.Шәймөхәммәтов, III дәрәҗә Хезмәт Даны ордены кавалерлары Р.Ә. Борһанов, И.В.Минһаҗев, И.М.Малайрэу, күп медальләр белән бүләкләнгән А.Г.Шутов, С.Х. Габдрахманов, Н.В.Коновалов һәм башка бик күпләр бар - барысын да санап бетерү мөмкин түгел. Бу көннәрдә аларның күбесе Ромашкино нефть ятмасын үзләштерүнең 50 еллыгына багышланган тантаналарда катнаша.

Коллектив ел саен яңара, тулылана.

Иң эре бораулау цехларының берсенә Локман Ильяс улы Хәмматов җитәкчелек итә. Ул безгә 1984 елда килгән иде. Укыды, үсте, эшкә өйрәнде. Бүген ул акыллы, сәләтле һәм ихтирам казанган җитәкче.

Бораулау остасы - "Татнефть" АҖ Почетлы нефтьчесе" һәм Татарстанның атказанган нефтьчесе М.И. Хәсәншин, бораулаучылар В.Х.Алтынбаев, А.Х.Мөхетдинов һәм башкалар үзләренең белем һәм тәҗрибәләрен оста файдаланып эшлиләр.

Автотранспорт цехы начальнигы В.А.Показаньев, вышка монтажлау цехы начальнигы И.Н.Стручков, автокран машинисты В.Х.Конышев, трактор краны машинисты С.Ш.Шакирҗанов, бораулаучы С.А.Соколов, электромонтер Ә.Ш.Мөхетдинов, вышка монтажлаучы Р.З.Хәмәтвәлиев, сылаучы - буяучы В.И.Петрова һәм башкалар үрнәк хезмәт итәләр.

1997 елның 1 апреленнән НУРБ "Татнефть"нең сервис предприятиесе ролен үти. Ә бүгенге бәйрәм ил өчен дә, коллектив өчен дә бик авыр чорга туры килде. Шулай да нефть эзләүчеләрнең кәефе бөтенләй үк төшенке түгел. Быелның сигез аенда проходка планы 111,1, шул исәптән разведка бораулавында 100, эксплуатация буенча 111,9 процентка үтәлде. Заказчыларга 46 скважина тапшырылды һәм бу планга карата 109,4 процент дигән сүз. Төрле һөнәри осталык конкурсларында сәләтләрен күрсәткән бораулаучыларыбызның фидакарьлеге нәтиҗәсе дә булып тора бу.

Финанс - икътисад авырлыклары безнең коллективны да бик кыен хәлләргә куя. Әмма бар максат - коллективны саклап калу, идарәнең арка терәге булган осталарны югалтмау.

**Т.ӘХМӘТҖАНОВА.**

# ТВ

## ПОНЕДЕЛЬНИК

### 7 СЕНТЯБРЯ

**«ТАТАРСТАН»**

**7.00 -8.00 "Чулпан"**
**18.10 Балалар өчен. "Туган телем - үз телем"**
**18.35 Музыка ТРТ**
**18.45,20.45 "Җиһан"**
**19.00 "Ислах"**
**19.45,21.45 Новости**
**20.00 Круглый стол. "Закон о занятости населения РТ"**
**20.30 "Тамчы"**
**21.00 "Дуэнья"**

**ОРТ**

6.00 "Доброе утро".
9.00 12.00 15.00 18.00 0.55 Новости.
9.15 18.20 "Роксолана - пленница султана".
9.55 "Поле чудес".
10.55 Здоровье.
11.20 Домашняя библиотека.
11.30 19.30 Угадай мелодию.
12.15 "Вместе".
13.00 Х/ф."Человек с бульвара Капуцинов".
15.20 "Тин-Тин идет по следу".
15.45 Марафон-15.
16.05 Звездный час.
16.40 "Лето наших надежд".
17.10 "...До 16 и старше".
17.30 "Вокруг света".
19.05 Час пик.
20.00"Человек в маске"
20.45 "Спокойной ночи, малыши!"
21.00 Время.
21.40 "Горец".
22.50 "Жизнь замечательных людей".
23.25 Х/ф "Любить".

**«РОССИЯ»**

7.00 Доброе утро ,Россия.
9.15 23.45 "Дежурная часть".
9.30 19.30 "Марьина роща"
9.55 "Стронг" представляет.
10.00 На заметку.
10.05 Товары-почтой.
10.10 "Санта-Барбара"
11.00 14.00 17.00 20.00 0.00 Вести.
11.30 "Преступление со многими неизвестными".Х/ф.
12.35 У всех на устах.
13.00 Старая квартира
14.30"Устроим себе рай"Х/ф.
16.15 "Позвоните Кузе!"
16.30 "Первые поцелуи".
17.30 Башня.
18.05 Любовь с первого взгляда.
18.30 "Доктор Марго"
20.30 Подробности.
20.45 Сам себе режиссер.
21.15"Невеста из Парижа".Х/ф
22.45 Акуна Матата.
0.30 Автошоу.

**РИО**

17.05 ДИСК-канал. 17.30 ТСН-6. 17.35 Дорожный патруль.17.50 Те Кто. 18.10 НОВОСТИ. 18.15"Дэвис учит жить", 26 серия. 18.50 "Дежурная аптека III", 32 серия. 19.30 НОВОСТИ. 19.35 Ток-шоу "АКУЛЫ ПОЛИТПЕРА". 20.30 "НОВОСТИ ДНЯ". 20.55 "Бриско Каунти. Приключения на Диком Западе", 20 серия. 21.50 НОВОСТИ. 21.55 "Лев Гурыч Синичкин". 23.30 ТСН-6. 23.35 Дорожный патруль. 23.50 ДИСК-канал. 0.35 "Знак качества".

## ВТОРНИК

### 8 СЕНТЯБРЯ

**«ТАТАРСТАН»**

**7.00-8.00 "Чулпан"**
**18.10 Мультфильмы**
**18.35 Музыка ТРТ**
**18.45,20.45 "Җиһан"**
**19.00 Борынгы халык җырлары. Рафаэль Ильясов башкара.**
**19.45,21.45 Новости**
**20.00 "Замандаш"**
**20.30"Әлли-бәлли-бәү"**
**21.00 "Самурай"**
**22.50 "Бизнес ТВ**

**ОРТ**

6.00 "Доброе утро".
9.00 12.00 15.00 18.00 0.25 Новости.
9.15 18.20 "Роксолана - пленница султана".
10.00 "Человек в маске".
10.45 Смехопанорама
11.20 Домашняя библиотека.
11.30, 19.30 Угадай мелодию.
12.15 "Вместе".
13.00 "Русский транзит".
14.10 Умники и умницы.
15.20 "Тин-Тин идет по следу".
16.00 Счастливый случай.
16.40 "Лето наших надежд".
17.10 "...До 16 и старше".
17.30 "Вокруг света".
19.05 Час пик.
20.00 "Тема".
20.45 "Спокойной ночи, малыши!"
21.00 Время.
21.40 "Человек-амфибия".
23.40 "Песня года".
0.40 "Как славно быть пиратом".Х/ф.

**«РОССИЯ»**

7.00 Доброе утро ,Россия.
9.15 23.45 "Дежурная часть".
9.30 19.30 "Марьина роща"
9.55 Медицинский вестник.
10.00 На заметку.
10.05 Товары-почтой
10.10 "Санта-Барбара"
11.00 14.00 17.00 20.00 0.00 Вести.
11.30 "Преступление со многими неизвестными".Х/ф.
14.35"Как быть любимой"Х/ф.
16.15 "Позвоните Кузе!"
16.30 "Первые поцелуи".
17.35 Башня.
18.05 Кроссворд.
18.30 "Доктор Марго"
20.30 Подробности.
20.45 "Аншлаг"представляет.
21.15"Хозяин тайги" Х/ф
22.50"Пси фактор"
0.30 Живая коллекция.

**РИО**

17.05 ДИСК-канал. 17.30 ТСН-6. 17.35 Дорожный патруль. 17.50 Те Кто. 18.15 НОВОСТИ. 18.20 "Дэвис учит жить", 27 серия. 18.50 "Дежурная аптека III", 33 серия. 19.30 НОВОСТИ. 19.35 Ток-шоу Артура КРУПЕНИНА 20.30 "НОВОСТИ ДНЯ". 20.55"Бриско Каунти. Приключения на Диком Западе", 21 серия. 21.50 НОВОСТИ. 21.55 "Ответный огонь" (США-Канада). 23.45 ТСН-6. 23.55 Дорожный патруль. 0.10 ДИСК-канал. 0.55 "Знак качества". 1.05 "Убить любой ценой".Х/ф.

## СРЕДА

### 9 СЕНТЯБРЯ

**«ТАТАРСТАН»**

**7.00-8.00 "Чулпан"**
**18.10 Мультфильмы**
**18.35 Музыка ТРТ**
**18.45,20.45 "Җиһан"**
**19.00 "Сельские будни"**
**19.25 "Моңсар" ансамбле концерты**
**19.45,21.45 Новости**
**20.00"Карт- бланш"**
**20.30"Әлли-бәлли-бәү"**
**21.00 "Сто дней после детства"**
**22.45"Точка опоры"**

**ОРТ**

6.00 "Доброе утро".
9.00 12.00 15.00 18.00 0.25 Новости.
9.15 18.20 "Роксолана - пленница султана".
10.00 Тема.
10.45 В мире животных.
11.20 Домашняя библиотека.
11.25 Джентльменшоу.
12.15 "Вместе".
13.00 "Русский транзит".Х/ф.
14.10 Умники и умницы.
15.20 "Тин-Тин идет по следу".
15.45 "Классная компания".
16.15 Зов джунглей.
16.40 "Новые приключения Синдбада".
17.10 "...До 16 и старше".
17.30 "Вокруг света".
19.00 Футбол.
19.50 "Спокойной ночи, малыши!"
21.00 Время.
21.40"Анна Каренина"
0.40Х/ф "Багз-2"

**«РОССИЯ»**

7.00 Доброе утро ,Россия.
9.15 0.30 "Дежурная часть".
9.30 19.30"Марьина роща"
9.55 Нефть.
10.00 На заметку.
10.05 Товары-почтой
10.10 "Санта-Барбара"
11.00 14.00 17.00 20.00 0.00 Вести.
11.35 "Звезда пленительного счастья"Х/ф
13.00 Старая квартира
14.35"Белый пароход"Х/ф.
16.15 "Позвоните Кузе!"
16.30 "Первые поцелуи".
17.35 Башня.
18.05 Кроссворд.
18.35 "Доктор Марго"
20.30 Подробности.
20.45"Два рояля".
21.30"Навахо блюз" Х/ф
23.05 "Агата Кристи. Пуаро".
0.45 Горячая десятка.

**РИО**

17.05 ДИСК-канал. 17.30 ТСН-6. 17.35 Дорожный патруль. 17.50 Те Кто. 18.15 НОВОСТИ. 18.20 Юмористический сериал "Дэвис учит жить", 28 серия. 18.55 Сериал "Дежурная аптека III", 34 серия. 19.30 НОВОСТИ. 19.35 Ток-шоу "Я САМА" . "Красавец - мужчина". 20.30 "НОВОСТИ ДНЯ". 20.55 "Бриско Каунти. Приключения на Диком Западе", 22 серия. 21.50 НОВОСТИ. 21.55 . "Современные девчонки" 23.35 ТСН-6. 23.45 Дорожный патруль. 0.00 ДИСК-канал. 0.45 "Знак качества". 1.00"Элис, милая Элис"

## ЧЕТВЕРГ

### 10 СЕНТЯБРЯ

**«ТАТАРСТАН»**

**7.00-8.00 "Чулпан"**
**18.10 "Мультфильмы**
**18.20 "За вас, за нас, за газ". Альметьевское предприятие ЛПУМГ "Таттрансгаза"**
**18.35 Музыка ТРТ**
**18.45,20.45 "Җиһан"**
**19.00 "Энергетический институт на пороге нового века"**
**19.25"Эхо голоса твоего"**
**19.45,21.45 Новости**
**20.00 "ГАИ- информ"**
**20.15 "Агым"**
**20.30"Әлли-бәлли-бәү"**
**21.00"Через Париж"**
**22.35 "Клуб Болл"**

**ОРТ**

6.00 "Доброе утро".
9.00 12.00 15.00 18.00 0.20 Новости.
9.15 18.20 "Роксолана - пленница султана".
10.00 Черноморские пираты XX века.
10.45 Пока все дома.
11.20 Домашняя библиотека.
11.25 19.30 "Эти забавные животные"
12.15 "Вместе".
13.00 "Вход в лабиринт". Х/ф.
14.20 Жизнь замечательных людей.
15.20 "Невероятные приключения Джонни Квеста"
15.45"Классная компания".
16.15 Детские анекдоты.
16.40 "Новые приключения Синдбада".
17.10 ...До 16 и старше.
17.30 Вокруг света.
19.05 Час пик.
20.05 Клуб "Белый попугай".
20.45 "Спокойной ночи, малыши!"
21.00 Время.
21.40 "Законный брак".
23.35 "Тринадцать чемпионов" . Х/ф
0.35"Багз-2".Х/ф.

**«РОССИЯ»**

7.00 Доброе утро ,Россия.
9.15 0.30 "Дежурная часть".
9.30 19.30 "Марьина роща"
9.55 Мир здоровья.
10.00 На заметку.
10.05 Товары-почтой.
10.10 "Санта-Барбара"
11.00 14.00 17.00 20.00 0.00 Вести.
11.35 "Звезда пленительного счастья".
13.00 Старая квартира
14.35"Униженные и оскорбленные"Х/ф.
16.15 "Позвоните Кузе!"
16.30 "Первые поцелуи".
17.35 Башня.
18.05 Лабиринт.
18.35 "Матери, жены и любовницы"
20.30 Подробности.
20.45 "Добрый, вечер!"
21.15"Безумный".Х/ф
23.00 "Притворщик".
0.45 Чемпионат мира по вольной борьбе.

**РИО**

17.05 ДИСК-канал. 17.30 ТСН-6. 17.35 Дорожный патруль. 17.50 Те Кто. 18.15 НОВОСТИ. 18.20 "Дэвис учит жить", 29 серия. 18.50 "Дежурная аптека III", 35 серия. 19.30 НОВОСТИ. 19.35 Ток-шоу "СДЕЛАЙ ШАГ". 20.30 "НОВОСТИ ДНЯ". 20.55 "Бриско Каунти. Приключения на Диком Западе", 23 серия. 21.50 НОВОСТИ. 21.55 Фильм "Прости". 23.35 ТСН-6. 23.45 Дорожный патруль. 23.55 ДИСК-канал. 0.40 "Знак качества". 0.55 "Свидание вслепую" (США).

## ПЯТНИЦА

### 11 СЕНТЯБРЯ

**«ТАТАРСТАН»**

**7.00-8.00 "Чулпан"**
**18.05 "Энҗе бөртекләре"**
**18.35 Музыка ТРТ**
**18.45,20.45 "Җиһан"**
**19.00 "Батулла дәресләре"**
**19.20 "Дин һәм тормыш"**
**19.45,21.45 Новости**
**20.00 "Ильдан" сегодня**
**20.15 "Музыкаль сәхифә"**
**20.30 "Әлли - бәлли - бәү"**
**21.00 "Җомга көн кич белән"**
**22.00 "Лидия Әхмәтова концерты**

**ОРТ**

6.00 "Доброе утро".
9.00 12.00 15.00 18.00 0.20 Новости.
9.15 18.20 "Роксолана - пленница султана".
10.05 Клуб путешественников.
10.55 Смак.
11.15 Домашняя библиотека.
11.25 "Играй, гармонь любимая!".
12.15 "Вместе".
13.00 "Вход в лабиринт".
14.10 Умники и умницы.
15.20 "Сказка, рассказанная ночью".
16.35 "Улица Сезам".
17.05 "Чердачок Фруттис".
17.30 "Вокруг света".
19.10 Здоровье.
19.45 "Поле чудес".
20.45 "Спокойной ночи, малыши!"
21.00 Время.
21.40 "Смерть в объективе".Х/ф.
23.35 Взгляд.
0.35 "Исповедь содержанки".Х/ф.

**«РОССИЯ»**

7.00 Доброе утро ,Россия.
9.15 23.40"Дежурная часть".
9.30 19.30 "Марьина роща"
9.55 Мир здоровья.
10.00 На заметку.
10.05 Товары-почтой.
10.10 "Санта-Барбара"
11.00 14.00 17.00 20.00 0.00 Вести.
11.35 Памяти Альфреда Шнитке.
12.30 Тысяча и один день.
12.50 Старая квартира
13.45 Торговый дом "Ле Монти".
14.35"Мой лучший друг-генерал Василий, сын Иосифа"Х/ф.
16.15 "Позвоните Кузе!"
16.30 "Первые поцелуи"
17.35 Башня.
18.05 У всех на устах.
18.35 "Матери, жены и любовницы" Х/ф.
20.30 Подробности.
20.45 "Аншлаг" и Ко.
21.45"Молодые стрелки".Х/ф
0.30 "Валентино возвращается" .Х/ф.

**РИО**

7.05 ДИСК-канал. 17.30 ТСН-6. 17.35 Дорожный патруль. 17.50 Видеоклипы. 18.00 Те Кто. 18.50 "Дежурная аптека III", 36 серия. 19.30 НОВОСТИ. 19.35 КАТАСТРОФЫ НЕДЕЛИ. 20.05 "ВЫ - ОЧЕВИДЕЦ". 20.30 "НОВОСТИ ДНЯ". 20.55 "К сокровищам авиакатастрофы". 22.50 "ОБОЗ". 23.50 "Такси ТВ-6". 0.05 ТСН-6. 0.15 Дорожный патруль. 0.30 ДИСК-канал. 1.15 "Знак качества". 1.30 "Китайский шоколад" Х/Ф.

## СУББОТА

### 12 СЕНТЯБРЯ

**«ТАТАРСТАН»**

**7.00-8.00 "Чулпан"**
**17.05 "Садко"**
**18.35 Музыка ТРТ**
**18.45 "Җиһан"**
**19.00 "Бизнес ТВ"**
**19.45 Новости**
**20.00 "Нижнекамск. Признание в любви"**
**20.30"Әлли-бәлли-бәү"**
**20.45 "Музыка плюс"**
**21.30 "Видеоспорт-авто"**
**22.00 "Илһам. Вдохновение"**
**22.50 "Точка опоры"**

**ОРТ**

8.00 "Золотой эшелон". Х/ф.
9.45 Слово пастыря.
10.00 15.00 18.00 Новости.
10.10 Домашняя библиотека.
10.30 "Утренняя почта".
11.05 "Каламбур".
11.40 Смак.
12.00 "Возвращение Третьяковки".
12.30 Радзинский о Татьяне Дорониной .
13.20 "Валентин и Валентина".Х/ф.
15.20 "Цивилизация".
15.50 В мире животных.
16.25"Альфред Шнитке.Портрет с друзьями" .
17.15 Как это было.
18.25 Джентльмен-шоу.
19.00 "Приключения мистера Питкина в больнице".
20.45 "Спокойной ночи, малыши!".
21.00 Время.
21.40 "Схватка."
0.45 "Любовная драма в "Барселоне ".

**«РОССИЯ»**

8.00 Мультфильм.
8.10 "Семь воронов"
9.30 "Лабиринт".
10.00 Доброе утро, страна!
10.45 Кроссворд.
11.15 "Любовь с первого взгляда".
11.45 Сиреневый туман
12.35 "Домашние хлопоты Наталии Варлей".
13.00 "Неделя в Санта-Барбаре".
14.00 20.00 Вести.
14.30 "Плохой хороший человек".
16.10 "Закон и порядок"
17.00 "Звезда Шерифа".
19.00 Моя семья.
20.30 Добрый вечер с Угольниковым .
21.15 "Гений".Х/ф.
0.00 "И корабль плывет".

**РИО**

7.05 Дорожный патруль. 7.20 ДИСК-канал. 8.05 М/ф "Ох и Ах". 8.15"Капитан Пилигрима". 9.55 ТЕЛЕМАГАЗИН 10.05 "РобинГуд"11.05 0.15"З.К." 11.30 ТСН-6. 11.45 "Мальва". 13.15 ТЕЛЕМАГАЗИН 13.35 Мультфильм. 13.50 "Нью-Йорк, Нью-Йорк". 14.25 "Еще раз про любовь". 16.10 "Такси ТВ-6". 16.25 Видеоклипы. 16.40 ДИСК-канал. 17.30 0.40 ТСН-6. 17.35 Дорожный патруль. 17.50 Путешествия с "Национальным Географическим Обществом" . 18.55 "Звезды о звездах" . 19.25 Видеоклипы. 19.40 "О.С.П. - Студия". 20.30 СКАНДАЛЫ НЕДЕЛИ. 21.00 "Фитиль". 21.40 "Кавказский пленник". 23.15 Церемония вручения премии "100-пудовый хит" от ХИТ-FM. 0.50 "Такси ТВ-6". 1.05 "Донор"

## ВОСКРЕСЕНЬЕ

### 13 СЕНТЯБРЯ

**«ТАТАРСТАН»**

**7.00 - 8.00 "Чулпан"**
**17.40 "Йолдызлар һәм йолдызчыклар"**
**18.20 "Видеоспорт"**
**18.35 Музыка ТРТ**
**18.45 "Телебуклет"**
**19.00 "ТОН"**
**19.40 "Автокалейдоскоп"**
**20.00 "Ханым"**
**20.30"Әлли-бәлли-бәү"**
**20.45 Т.Миңнуллин. "Кырларым - тугайларым". Казан дәүләт педагогика университеты яшьләр театры спектакле.**

**ОРТ**

8.00 "Утреннее шоссе".
9.30 16.45 "Дисней-клуб".
10.00 15.00 0.15 Новости.
10.10 "Непутевые заметки".
10.30 Пока все дома.
11.10 Утренняя звезда.
12.00 "Служу России!"
12.30 "Играй, гармонь любимая!".
13.00 Крестьянские ведомости.
13.30 "Подводная одиссея команды Кусто".
14.25 Смехопанорама.
15.20 Клуб путешественников.
16.10 Футбольное обозрение.
17.40 "Колесо истории".
18.25 "Ералаш" .
19.05 "Свой среди чужих, чужой среди своих".
21.00 Время.
21.35 "Роман с камнем".
23.45 "Абажур".
0.25"Два придурка с поросенком":Х/ф.

**«РОССИЯ»**

8.00 "Красная книга".
8.30 "Служу Отечеству!"
9.00 Утро крестьянина.
9.30 Маски-шоу.
10.00 Доброе утро, страна!
10.35 Сам себе режиссер.
11.05 "Аншлаг" представляет.
12.00 Русское лото.
12.45 "Мир книг с Л.Куравлевым".
13.00 "Неделя в Санта-Барбаре".
14.00 Вести.
14.30 Федерация.
15.15 Парламентский час.
16.10 "Закон и порядок".
17.00 Диалоги о животных.
18.00 Старая квартира.
19.05 Совершенно секретно.
20.00 Зеркало.
20.55 "Лолита".Х/ф.
23.15 "К-2" представляет.
0.10 Кольцевые автогонки.
0.25 Чемпионат мира по вольной борьбе.

**РИО**

7.05 Дорожный патруль. 7.20 ДИСК-канал. 8.05 М/ф "Про козла". 8.25 . "Самый сильный". 9.55 "Робин Гуд" 10.55 Шоу еды 11.30 ТСН-6. 11.45 "Живой щит". 13.25 ТЕЛЕМАГАЗИН 13.40 М/ф" 13.55 "КАНОН". 14.30 Ток-шоу "Я САМА" . 15.30 Документальный сериал . 15.55 "Такси ТВ-6". 16.10 Телемагазин. 16.15 "Весь мир товаров в ГУМе". 16.20 СПОРТ НЕДЕЛИ. 17.00 "НАЗЛО РЕКОРДАМ!". 17.30 ТСН-6. 17.40 Сводка за неделю. 17.50 Путешествия с "Национальным Географическим Обществом" 19.00 "ОБОЗРЕВАТЕЛЬ". 20.05 "Фитиль". 20.15 "Соммерсби". 22.35 "Шоу Бенни Хилла", 25 серия. 23.05 "Такси ТВ-6". 23.20 Навстречу фестивалю. 23.40 . "Полет голубки".

# НУРЛАТТА - СӘНГАТЬ МӘКТӘБЕ

(Ахыры. Башы 1 нче биттә).

Бәйрәмчә күтәренкелек рухы дәвам итте. ТРның мәдәният министры М.М.Таишевның чыгышы:

- Республикадагы 122 мәктәп арасында сезнеке иң зурлардан санала. Рәхмәт хисләре белән килегез, белем алып таралышыгыз! - дип тәмамланды. "Татнефтепром" берләшмәсе генераль директоры Р.К. Зарипов, "Татспиртпром" җитештерү берләшмәсе генераль директоры Р.Р.Шәйхетдинов та җылы котладылар, алдагы чыгыш ясаучылар кебек үк бүләкләр тапшырдылар. Сәнгать мәктәбе директоры Т.С.Бадыйгинның дулкынланган шатлыклы чыгышы да яңгырады. Аңа ата - аналар исеменнән Р.В.Яруллина чыгышы өстәлде, мәдәният хезмәте ветераны К.В. Изотова эчкерсез сөенечен белдерде. Балаларның шигъри котлавыннан һәркемнең күңеле нечкәрде. Ә аннары 547нче ПМК мастеры Ф.М.Мингалимов бинаның яңа хуҗаларына символик ачкыч тапшырды, аны бүгенгедәй тәртиптә тотарга чакырды. Ә моңа хакы бар иде мастерның. Төзүчеләр бинаны төзүдә, бизәүдә иң таләпчән хуҗалар зәвыгына да җавап бирерлек сыйфатны сакларга тырыштылар, аларның һәр киңәшенә колак салдылар. Шуңа район хакиме төзүчеләрнең иң уңганнары - мастерның үзенә, штукатур - буяучы Г.Л.Овчинниковага, балта остасы И.Р.Галиев, ташчы А.И.Салятдиновка Мактау грамоталары һәм истәлекле бүләкләр тапшырды.

Ниһаять, иң тантаналы мизгелләр җитте. Ф.Х.Мөхәммәтшин һәм Ф.С.Сибагатуллин мәктәпкә юл ачасы ал тасманы кистеләр һәм халык ташкыны эчкә юл алды.

Әйе, сокланырлык, таң калырлык булып чыккан шул ул! Матур бизәлгән стеналар, бүлмәләр үзе үк балаларда зәвык тәрбияләрлек. Һәр төр занятие өчен аерым класслар, алар тиешенчә җиһазланган. Бирегә 10 пианино, 4 рояль генә бар, аның берсе - "Россия" мәһабәт концерт рояле бар шартларына туры китереп төзелгән концерт залына урнаштырылган. Залның урындыклары гына да 250 мең сумга төшкән!

Яңа мәктәп балаларны тагын ни белән сөендерәчәк соң?

Иркенлек рәсем сәнгате бүлеге ачарга, анда 30лап бала алырга, тынлы оркестр - кларнет, гобой, саксофон, труба, флейта классларына укучылар тупларга мөмкинлек бирәчәк. Быел 2 хореография классы эшләячәк, алда саналганнарның һәммәсенә хәзер дә балалар кабул ителә. Бер сүз белән әйткәндә, быел гына да мәктәптә сәнгать белеме алучылар саны 200гә артачак. Әле аның киләчәге дә бар бит!

Кунаклар, тантанада катнашучыларны дулкынландырырлык хәбәрләр иде болар. Алар яңа концерт залында беренче чыгышларны да карадылар. Мәктәпне тәмамлаучы Н.Фадеева яңа концерт роялена сак кына кагылган иде - залга кодрәтле моң - музыка таралды, ул уйларны бөтереп алды, җаннарны дулкынландырды, гаҗәеп илаһи, сихерле дөнья - музыка дөньясы тудырды.

Бу бина шул сихри моңнары белән күп нәниләрнең яшь күңеленә матурлык, игелек орлыклары сибәр, зәвык тәрбияләр, бай рухлы шәхес нигезләре салыр әле. Ә сәламәт рухлы кешеләр җәмгыятькә һәрчак кирәк.

Хәерле сәгатьтә, сәнгать мәктәбе!

Изге багланышыңа тугры бул!

**С.ХӘЙРУЛЛИНА.**

## "ӘКИЯТ"ТӘ БЕРЕНЧЕ КЫҢГЫРАУ

***"Әкият" башлангыч мәктәп - бакчасы быел икенче уку елын каршы алды. Белем көнендә иртәнге линейкага барлыгы 16 класс, ягъни 250 укучы тезелде. Ике сыйныф балалары гыйлем дөньясына тәүге адымнарын ясадылар.***

Тантаналы линейкада мәктәп - бакча директоры Р.Г.Карымованың чыгышы озын булмады: иң мөһиме, ул яңа уку елында укучыларның яңа ныклы көч һәм тырышлык куеп эшләүләрен теләде һәм быел мәктәпнең аларны каршы алырга, һәм катлаулы белем баскычларына алып менәргә әзерлеген җиткерде. Соңгысына килгәндә, мәктәп - бакча быел чынлап та күпләр көнләшерлек биеклеккә ирешә алды: яңа 1998 - 99нчы уку елына әзерлек буенча башлангыч мәктәпләр арасында беренче урынны алды. Ашханә, табигать почмагы, театр һәм рәсем сәнгате студияләре, туган як музее, юл хәрәкәте куркынычсызлыгы бүлмәсе һәм тагын башкалар - һәммәсе дә төптән уйланып, оста кул һәм камил зәвык белән эшләнгән. "Дәрес, тагын башка кабинетлар ачу буенча да ниятләр юк түгел,- ди Римма Гәрәевна,-ләкин мәктәпнең тыгызлыгы күп нәрсәгә киртә куя. Бирегә бит микрорайон укучылары гына түгел, әфганчылар поселогыннан да киләләр". Кызганычка каршы, шул тыгызлык аркасында мәктәпнең янында гына яшәүче шактый бала башка бакча һәм мәктәпләргә йөрергә мәҗбүрләр. Ә менә икенче катлаулы мәсьәлә - белгечләрнең җитенкерәмәве тулысынча булмаса да быел хәл ителгән: татар теле буенча ике белгеч, инглиз теле, физкультура укытучылары бар быел. Шуңа да быелгы уку елында җитәкчелек ике класста инглиз телен укытырга, икесендә музыканы тирәнтен өйрәтергә ниятли. Быелга 3 класс татар телендә белем алачак, ә беренче классларның берсендә тәрбия чаралары, аралашу туган телләрендә алып барылачак.



**Ф.ГАЛИМОВА.**

## БЕЛЕМ КӨНЕ

*Каравыл Тавы урта мәктәбендә белем көне традицион гомуммәктәп линейкасыннан башланып китте. Мәктәп директоры Л.И. Арбузова һәм Кузнецов исемендәге кооператив рәисе М.З.Фәхретдинов барысын да белем көне белән кайнар котладылар. М.З.Фәхретдинов җәйге каникул вакытында хуҗалыкта эшләгән укучыларга кыйммәтле бүләкләр тапшырды. Мәктәпнең уку - укыту эшләре буенча директор урынбасары Г.А.Игнатьева узган уку елына йомгак ясады һәм аны бик яхшы тәмамлаган укучыларны билгеләде.*

*Болар барысы да балаларның мәктәп турындагы җырлар һәм шигырьләре белән бергә алып барылды.*

*Көннең төп геройлары, билгеле, беренче класс балалары иде. Алар бу көнне үзләренең хәтерләрендә мәңге саклар дип ышанасы килә. Истә калырлык нәрсәләр бик күп иде: беренче китап, тәүге дәрес, аларны тылсымлы да кызыклы да белем дөньясына алып кергән беренче укытучылары.*

*Хәерле сәгатьтә!*

***Т.ГРАФ,***
***балалар - яшүсмерләр үзәге методисты.***


## БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА. БЕЛДЕРҮЛӘР

### Казан бизнес һәм идарә институтының Шантала филиалы

***1998 - 99 уку елына икътисад факультетына түбәндәге белгечлек буенча студентлар кабул итә башлый:***

***- икътисадый юнәлешле менеджмент.***

***Уку читтән торып. Уку срогы:***

***- урта мәктәп базасында 5 ел;***

***- югары һәм тулы булмаган югары (махсус урта) белемлеләргә 3 ел.***

***Институтка кабул итү әңгәмә һәм тест рәвешендә үткәрелә. Уку түләүле. Документлар түбәндәге адрес буенча кабул ителә:***

Самара өлкәсе, Шантала станциясе, Л.Толстой ур., 53, тел.: 2-12-63.

РФ Югары белем министрлыгы тарафыннан 1994 елның 3 ноябрендә бирелгән № 16 -157 лицензия.

### Килми калмагыз, күрми калмагыз!

***10 сентябрьдә кич район мәдәният йорты сәхнәсендә популяр җырчы Нәфкать Нигъмәтуллин "Үзем белгән юл белән" дигән концерт программасы тәкъдим итә. Концерт җыр - биюгә дә, нәфис сүзгә дә бай булачак.***

Башлана кичке сигезенче яртыда.

Билет хакы 15 сум.


## БЕЛҮЧЕ ЮКМЫ?

***3 сентябрьдә кичке сәгать 9лар тирәсендә чистарту корылмалары ягында юлда тән җәрәхәтләре булган, 40 - 45 яшьләрдәге бер хатын - кыз табылды. Әлеге яралар нәтиҗәсендә ул хастаханәдә вафат булды. Бу хакта ни дә булса белүчеләрнең район эчке эшләр бүлегенә хәбәр итүләрен үтенәбез.***

Телефоннар: 2-11-25 яки 02.


## БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА. БЕЛДЕРҮЛӘР

### САТАБЫЗ

**Ашыгыч төстә шәһәр үзәгендә ике бүлмәле фатир, 1995 елгы "Нива".** ДАИ янындагы техник хезмәт күрсәтү станциясенә (тел.: 5-16-40) яки Гагарин ур., 12 - 2 адресы буенча (тел.: 2-16-19) мөрәҗәгать итәргә.

***

**1990нчы елгы ВАЗ - 21083, кыйммәт түгел, Киекледә дача өчен йорт.** Тел.: 5-22-39.

***

**"Наратлык" ширкәтендә (Каравыл Тавы) дача участогы.** Тел.: 2-13-28.

***

**Арзан бәягә рамнары белән тәрәзә блоклары.**
4нче мәктәпкә мөрәҗәгать итәргә.

***

**1 - 2 көн эчендә 450 - 550 сум белән мәрмәр кыйпылчыклардан язулы, 1,2 x 0,6лы 2500 - 3000 сум белән кара граниттан портретлы кабер ташлары эшләп бирәм.** Адрес: Ленинград ур., 14. Б - 324 таныклык.

***

**Некрасовкада дача.** Тел.: 5-22-81, кичке 4тән соң.

***

**Шәһәр үзәгендә ике бүлмәле фатир (беренче кат), телефоны, сарае, гаражы бар.** Тел.: 2-17-57.

***

**1990 елгы әйбәт хәлдәге, ак төстәге ВАЗ - 2106 (двигателе 1600ле).** Адрес: Чирмешән районы, Ульяновка авылы, Станислав Ефремовка.

***

**Бишекле "Иж - Планета - 5" мотоциклы, әйбәт хәлдәге мотоблок таккычы.** Тел.: 5-36-50, теләсә кайчан.

***

**Бассейн янында дача.** Тел.: 5-19-92.

***

**Силикат кирпеч һәм газобетон, кыйммәт түгел.**
Якушкино авылында Л.Матюшкинага мөрәҗәгать итәргә.

***

**Чанада гараж.** К.Маркс ур., 1 - 19.

***

**1998 елгы ВАЗ - 2106.** Тел.: 5-14-23.

***

**"Нарат" (элеватор) ширкәтендә дача участогы, мансардлы кирпеч йорты, мунчасы, базы, 9 еллык җиләк - җимеш куаклары бар.** Тел.: 2-19-13.

***

**Кер юу машинасы.** Тел.: 5-27-15.

***

**Ключи поселогында һәм шикәр заводында дача участоклары (арзан).** Адрес: Ленин ур., 28 - 1.

### *ЭКСПРЕСС - ҮЗӘК*

**Чит илдә чыккан теле - видео аппаратуралар ремонтлау буенча яңа хезмәт тәкъдим итә.**

***

**Сатуда һәрчак төрледән - төрле компьютерлар һәм аксессуарлар, оргтехника, фототоварлар, электр җиһазлары.**

***

**Компьютерлар һәм оргтехниканы ремонтлау һәм заманчалаштыру хезмәтләре күрсәтә.**

***

**А 4 форматта ксерокүчермәләр ясый.**

***

**Һәркөнне иртәнге 8дән кичке 6га кадәр эшли (төшке аш вакыты көндезге 1дән 2гә).**

Адрес: Нурлат шәһәре, Мәктәп ур., "Көнкүреш йорты", 2нче кат, тел.: 5-37-51.

**"Скинеф" Республика укыту - бизнес үзәге ЭВМ операторлары әзерләү курсына тыңлаучылар кабул итә.**

Адрес: Мәктәп ур., "Көнкүреш йорты", 2нче кат,тел.: 5-37-51.

### САТАБЫЗ ЯКИ АЛМАШТЫРАБЫЗ

**Шәһәр үзәгендә бер бүлмәле фатир, сигнализациясе, "Кенвуд" магнитофоны булган, салон эче ябыштырылган, юеш асфальт төсендәге 1994 елгы ВАЗ - 21093 сатыла яки ике бүлмәле фатирга алмаштырыла (шикәр заводы һәм тимер юл бистәләреннән тәкъдим итмәскә).** Адрес: Мәктәп ур., 14 - 6, кичке 7дән соң.

### ТӨРЛЕСЕННӘН

***13нче сентябрьдә иртәнге сәгать 10да Самара өлкәсенең Яңа Җүрәй (Файзуллово) авылында мәчет ачыла. Авылдашларны, якташларны шушы тантанага чакырабыз.***

***

**Яхшы төзүчеләр турында бушлай мәгълүмат бирәм. Сыйфатлы итеп йортлар, гаражлар, янкормалар төзиләр.** Тел.: 5-16-25 (Нәҗип).

***

***Некрасовка авылында никах балдаклары белән акча янчыгы табучының бүләк бәрабәренә шул авылдагы Фәйзуллинга кайтарып бирүен сорыйбыз.***

### БИРЕП ТОРАБЫЗ

**Кормышта бер бүлмәле фатир. Бер елга алдан түләп куярга.** Тел.: 5-16-74 (кичке 6дан 9га кадәр).


"Дуслык" ("Дружба", "Туслах") район газетасы редакциясе коллективы **апасы Валентина Ивановна ЕРМИШКИНАның** вакытсыз вафат булуы сәбәпле "Туслах" газетасы редакторы Т.И.Бурайкинаның авыр хәсрәтен уртаклаша.


БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА.**

Учредительләр:Нурлат район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Нурлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19.
Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

*ГазетаТатарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2361 данә. 3497